| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.08.2022 с.Старое Дрожжаное № 439

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең, авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләү шартларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 09 апрелендәге 170 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Үзәкләштерелгән бухгалтерия» муниципаль казна учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә, 1 нче таблицаны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| «Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 | |

| | | |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 25 500 |
| Бүлек башлыгы | 21 700 | 21 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 19 300 | 19 300 |
| Бухгалтер | 18 000 | 18 000»; |

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турындагы Нигезләмәдә 1 нче таблицаны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

| «Вазифа | Муниципаль берәмлекләрнең Башкарма комитетлары халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |
| Баш бухгалтер | 19 700 | 21 000 |
| Бухгалтер | | 18 500». |

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджетын формалаштырганда Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасына үзәкләштерелгән бухгалтерияләр хезмәткәрләренә хезмәт хакын арттыруга акчалар «Мәгариф» бүлеге, авыл җирлекләре бухгалтерлары буенча «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлеге (0113) буенча планлаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары И.Р. Измайловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов